**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

2025елнын 16 апреле 22 номер

# КАРАР

**Сокуры авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Газизуллинны отставкага җибәрү һәм аның вәкаләтләрен вакытыннан алдан туктату турында**

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге Советына кергән 2025 елның 8 апрелендәге 01-3731 номерлы җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2.1 пункты, 40 статьясындагы 10.1 өлеше һәм 74.1 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты нигезендә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 пунктларында һәм «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 7 өлеше белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуров авыл җирлеге Советы, 2021-2023 елларга керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү материалларын өйрәнеп, карар кылды:

1«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, бурычларны бозган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге башлыгы Газизуллин Руслан Наил улын отставкага җибәрергә.

2. 2025 елның 16 апрелендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге башлыгы һәм депутаты Газизуллин Руслан Наил улының вәкаләтләрен, ышанычны югалту сәбәпле, вакытыннан алда туктатырга,

3. Карар имзаланган көннән үз көченә керә.

**Сокуры авыл җирлеге**
**Советы рәисе урынбасары** **А.А.Халитов**